Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

КАРАР №XLIII-1

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 15 нче ноябре

Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасының «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 маддәсе. Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 94, 95, 96 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2022 елның 31 маендагы XXII-1 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда юстиция органнарына дәүләт теркәвенә җибәрергә.
3. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда, “Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар” Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) (http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф - челтәрле басма буларак теркәлү: Эл. N ФС77-72471 05.03.2018) һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсендәге 8 өлеше, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 96 маддәсендәге 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы Р.Р. Ислямов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2023 елның 15 нче ноябре
XLIII-1 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. Устав тексты буенча тиешле килештәге «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен тиңдәшле килештәге «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

2. 13 маддәдә:

2.1. 2 пункттагы «тавыш бирү» сүзеннән алда «депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затын чакыртып алу буенча тавыш бирү,» сүзләрен өстәргә;

2.2. түбәндәге эчтәлектәге 4 пунктны өстәргә:

«4) территориаль иҗтимагый үзидарә;»;

2.3. 4 – 10 пунктларны тиңдәшле рәвештә 5 – 11 пунктлар дип санарга;

2.4. түбәндәге эчтәлектәге 11 пунктны өстәргә:

«11) иҗтимагый (консультатив) советлар төзү;»;

2.5. 11 пунктны тиңдәшле рәвештә 12 пункт дип санарга.

3. 15 маддәне яңа кушымта редакциясендә бәян итәргә:

«15 маддә. Депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затын чакыртып алу буенча тавыш бирү, районның чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү

1. Депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затын чакыртып алу буенча тавыш бирү «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән һәм аның нигезендә кабул ителә торган җирле референдум уздыру өчен Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы ФЗ дагы үзенчәлекләрне исәпкә алып халык инициативасы буенча уздырыла.

2. Депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затын чакыртып алу нигезләре һәм күрсәтелгән затларны чакыртып алу процедурасы әлеге Устав белән билгеләнә.

Депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затын чакыртып алу өчен, аларны суд тәртибендә раслаган очракта, аның конкрет хокукка каршы карарлары яисә гамәлләре (гамәл кылмавы) гына нигез була ала.

Депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затын чакыртып алу процедурасы аңа сайлаучыларга чакыртып алу өчен нигез буларак күрсәтелә торган шартларга карата аңлатмалар

биру мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш. Әгәр чакыртып алу өчен районда теркәлгән сайлаучыларның кимендә яртысы тавыш бирсә, депутат, жирле үзидарәнен сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты чакыртып алынган дип санала.

2.1. Әгәр район Советындагы барлык депутат мандатлары яки депутат мандатларының бер өлеше сайлау берләшмәләре тәкъдим иткән кандидатлар исемлеге составында сайланган депутатлар тарафыннан алыштырыла (биләнә) икән, депутатны чакыртып алу кулланылмый.

3. Чикләрне үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү халыкның күрсәтелгән чикләрне үзгәртүгә, районны үзгәртеп коруга ризалыгын алу максатыннан үткәрелә.

4. Чикләрне үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү районның бөтен территориясендә яки аның территориясенең бер өлешендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән очракларда үткәрелә.

5. Район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү район Советы тарафыннан билгеләнә һәм «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел № 67-ФЗ Федераль законы һәм «Җирле референдум турында» 24.03.2004 ел № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып үткәрелә.

6. Район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү, әгәр анда сайлау хокукына ия булган район халкының яртысыннан артыгы яки районның бер өлеше катнашкан булса, уздырылган дип санала. Халыкның район чикләрен үзгәртүгә, районны үзгәртеп коруга ризалыгы, әгәр күрсәтелгән үзгәреш өчен тавыш бирүдә катнашкан район яки районның бер өлеше халкының яртысыннан артыгы тавыш биргән булса, алынган дип санала.

7. Чикләрне үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү йомгаклары һәм кабул ителгән карарлар рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.».

27 маддәдә:

3.1. 13 өлешнең үз көчен югалтуын танырга;

3.2. 7 өлешнең 2 пунктындагы а пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.3. 7 өлешнең 2 пунктындагы б пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга.

4. 30 маддәнең 1 өлешендәге 20 пунктын төшереп калдырырга.

5. 36 маддәдә:

5.1. 1 өлешкә түбәндәге эчтәлектәге 10 пунктны өстәргә:

«10) алты ай дәвамында рәттән район Советының барлык утырышларында җитди сәбәпләрсез депутатның булмавы;»;

5.2. 10 пунктны тиңдәшле рәвештә 11 пункт дип санарга.

6. 39 маддәдә:

6.1. 4 өлешнең 2 пунктындагы а пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.2. 4 өлешнең 2 пунктындагы б пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

7. 42 маддәдә:

7.1. 8 өлешнең 2 пунктындагы а пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

7.2. 8 өлешнең 2 пунктындагы б пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

8. 43 маддәдә:

8.1. 1 өлешнең 1 пунктына «,федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

8.2. 1 өлешнең 2 пунктында «яки дөрес булмаган яисә улы булмаган мәгълүмат бирү» сүзләрен «,федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, тулы булмаган мәгълүматны яисә дөрес булмаган мәгълүматны бирү» сүзләренә алыштырырга;

8.3. 2 өлешкә «,федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.

9. 57 маддәнең үз көчен югалтуын танырга.

10. 56 маддәдә:

10.1. 1 өлешнең 4 пунктында «,ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион уздыру» сүзләрен төшереп калдырырга;

10.2. 4 өлештә «билгеләнә» сүзенә «һәм вазыйфасыннан азат ителә» сүзләрен өстәргә;

11. 62 нче маддәне яңа кушымта редакциясендә бәян итәргә:

« 62 маддә. Муниципаль хезмәт вазыйфасы

1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы - әлеге Устав нигезендә барлыкка килә торган җирле үзидарә органындагы вазыйфа, җирле үзидарә органының яисә муниципаль вазыйфаны биләүче затның вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү буенча билгеләнгән даирә белән.

2. Муниципаль хезмәт вазыйфалары Татарстан Республикасы законы белән раслана торган Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

3. Җирле үзидарә органының штат расписаниесен төзегәндә һәм раслаганда, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрында каралган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемнәре (аталышлары) кулланыла.».

11. 63 маддәнең 3 өлешендә «Районның сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга.

12. 64 маддәдә:

12.1. 1 өлешнең 5 пунктында «,Районның сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

12.2. 3 өлешнең 4 пунктында «Районның сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

13. 65 маддәнең 2 өлешендә «Районның сайлау комиссиясе», «Районның сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;